**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Куакбаш авыл җирлегенең**
**Сходнево-Чертанлы торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендә узган «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны кардан чистарту (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы);Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы))

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 74 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 45.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 45 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Сходнево-Чертанлы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге сораулар буенча карарны:

2.1. Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны кардан чистарту (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы);Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы))

2.2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Куакбаш авыл җирлегенең 2018 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы торак пунктында гражданнар җыеннары нигезендә җыелган гражданнарның калган үзара салым акчаларын Тукай урамы буенча юлны чокырлы ремонтлауга, 18.11.2021 №2 торак пункт территориясен төзекләндерүгә юнәлтүгә ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны кардан чистарту (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы);Сходнево-Чертанлы авылындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы))

кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, К.Маркс ур., 15; Сходнево-Чертанлы авылы - Ирек ур., 5б йорт, авыл мәдәният йорты бинасы; Чүте авылы - Тынычлык урамы, 8а йорт, авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова